**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ**
**(IV чакырылыш)**

# КАРАР

IV чакырылыш чираттан тыш утырышы

2021 елның 17 феврале № 37 Урыссу штп

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә ниятләнгән хуҗалык һәм башка төр эшчәнлек алып баруның әйләнә – тирә мохиткә йогынтысын бәяләү буенча иҗтимагый фикер алышулар үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 июнендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Экология экспертизасы турында» 1995 елның 23 декабрендәге 174-ФЗ номерлы Федераль законга, «Россия Федерациясендә хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохиткә йогынтысын бәяләү хакындагы Нигезләмәне раслау турында» Россия Федерациясе Дәүләт экология комитетының 2000 елның 16 маендагы 372 номерлы Боерыгына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Советының 2020 елның 28 апрелендәге 18 июнендәге №18 карары белән кабул ителгән «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Советы карар кабул итә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә ниятләнгән хуҗалык һәм башка эшчәнлек алып баруның әйләнә-тирә мохиткә йогынтысын бәяләү буенча иҗтимагый фикер алышуларны оештыру һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында “Рәсми Татарстан” дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм порталы составында “Интернет” мәгълүмат-

телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы район Советының законлылык, регламент һәм җирлекләр Советлары белән үзара хезмәттәшлек буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы Ютазы
муниципаль районы Башлыгы -
Татарстан Республикасы
Ютазы район Советы Рәисе А. Ә. Шәфигуллин

Татарстан Республикасы
Ютазы районы Советының
2021 елның «17» февраленнән
№37 карары белән расланды

**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә ниятләнгән хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохиткә йогынтысын бәяләү буенча җәмәгать фикер алышуларын оештыру һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмә**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә җәмәгатьчелеккә экология экспертизасы объекты булып торучы хуҗалык һәм башка эшчәнлек турында һәм аның әйләнә-тирә мохиткә мөмкин булган йогынтысы турында мәгълүмат бирү максатларында Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында (алга таба - Ютазы районы) иҗтимагый фикер алышуларны әзерләүне һәм уздыруны оештыру мәсьәләләрен җайга сала.

1.2. Әлеге Нигезләмәдә түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

*Ниятләнгән хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохиткә мөмкин булган йогынтысын бәяләүнең милли процедурасы* - әйләнә-тирә мохиткә планлаштырылган хуҗалык һәм башка эшчәнлек йогынтысын бәяләүне уздыру һәм билгеләнгән хуҗалык һәм башка эшчәнлекне нигезли торган документациягә экология экспертизасын уздыру.

*Ниятләнгән хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохиткә йогынтысын бәяләү* (алга таба - ОВОС) - мөмкин булган уңайсыз йогынтыларны билгеләү, экологик нәтиҗәләрне бәяләү, иҗтимагый фикерне исәпкә алу, йогынтыны киметү һәм булдырмау чараларын эшләү ярдәмендә ниятләнгән хуҗалык һәм башка эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында экологик юнәлешле идарә карары кабул итүгә ярдәм итә торган процесс.

*Экология экспертизасы* - хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең экологик таләпләргә туры килүен билгеләү һәм экология экспертизасы объектын гамәлгә ашыруның мөмкин булган тискәре йогынтысын әйләнә-тирә табигать мохитенә һәм аларга бәйле социаль, икътисадый һәм башка нәтиҗәләрне кисәтү максатларында экология экспертизасы объектын төзүнең (гамәлгә ашыруның) мөмкин булуын билгеләү.

*Йогынтыны бәяләү буенча тикшеренүләр* - йогынтыны бәяләү максатларын гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматны җыю, анализлау һәм документлаштыру.

*Ниятләнгән хуҗалык эшчәнлеге һәм башка эшчәнлек* - әйләнә-тирә табигать мохитенә йогынты ясарга сәләтле һәм экология экспертизасы объекты булган эшчәнлек.

*Заказ бирүче* - ниятләнгән эшчәнлек буенча документлар әзерләү өчен әлеге төр эшчәнлеккә карата куелган норматив таләпләр нигезендә җавап бирүче һәм экологик экспертизага билгеләнгән эшчәнлек буенча документация күрсәтүче юридик яисә физик зат.

*Әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләү эшләрен башкаручы* - аңа заказчы әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләү буенча эшләр башкару хокукын биргән әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләүне уздыра торган физик яки юридик зат.

*Йогынты бәяләү материаллары* - әйләнә-тирә мохиткә билгеләнгән эшчәнлекнең йогынтысын бәяләүне уздырганда әзерләнгән һәм экологик экспертизага тапшырыла торган документациянең бер өлеше булып торган документация комплекты.

*Иҗтимагый фикер алышулар* - әлеге Нигезләмә һәм башка норматив документлар нигезендә йогынты ясауны бәяләү кысаларында үткәрелә торган чаралар комплексы, ул иҗтимагый өстенлекләрне ачыклау һәм йогынтыны бәяләү процессында аларны исәпкә алу максатыннан, җәмәгатьчелеккә хуҗалык һәм башка эшчәнлек турында хәбәр итүгә юнәлдерелгән.

1.3. Әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләүне уздыруның максаты булып әлеге эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохиткә йогынтысын һәм аңа бәйле социаль, икътисадый һәм башка нәтиҗәләрне булдырмау яисә йомшарту тора.

1.4. Әйләнә-тирәлеккә йогынтыны бәяләү, билгеләнә торган хуҗалык һәм башка эшчәнлек өчен үткәрелә, нигезләнә торган документлар «Экологик экспертиза турында» 23.11.1995 ел, № 174-ФЗ Федераль закон нигезендә, экологик экспертиза узарга тиеш. Әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләү буенча эшләр тәртибе һәм эчтәлеге, документлар составы билгеләнгән тәртиптә билгеләнгән эшчәнлекнең төрләре һәм (яисә) конкрет характеристикалары нигезендә Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары белән билгеләнә.

1.5. ОВОС буенча материаллар әзерләгәндә җәмәгатьчелекнең катнашуы түбәндәгечә гамәлгә ашырылырга мөмкин:

- башлангыч мәгълүматны бирү этабында;
- ОВОС үткәрү һәм нигезләүче документларны әзерләү этабында.

1.6. Ютазы районы территориясендә ОВОС буенча иҗтимагый фикер алышуларның предметы булып дәүләт экология экспертизасы объектының түбәндәге документациясе (алга таба - документлар) тора:

- билгеләнгән эшчәнлекнең гомуми тасвирламасын үз эченә алган нигезләүче документация; аны гамәлгә ашыру максатлары; мөмкин булган альтернативалар; аны гамәлгә ашыру шартларын тасвирлау; гамәлдәге норматив документларда каралган башка мәгълүмат;
- башлангыч ОВОС нәтиҗәләре;
- ОВОС үткәрүгә техник бирем;
- Дәүләт экология экспертизасы объектларына куела торган таләпләргә законнарда билгеләнгән таләпләргә туры килә торган ОВОС буенча материалларның башлангыч варианты.

1.7. Иҗтимагый фикер алышулар түбәндәге формаларда уздырыла:

- җәмәгать тыңлаулары;
- сораштыру;
- ОВОС материаллары белән таныштыру, кисәтүләр һәм тәкъдимнәр.

Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне халык белән турыдан-туры хәл иткән очракта, Ютазы районы Уставында билгеләнгән тәртиптә ОВОС буенча җирле референдум уздырыла.

1.8. Иҗтимагый фикер алышулар аларны үткәрү зарурлыгы турында түбәндәге субъектларның берсе генә булса да белдерсә (алга таба - инициаторлар), уздырыла:

- Татарстан Республикасы Ютазы район Советы;

- Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башлыгы - Татарстан Республикасы Ютазы район Советы Рәисе;

- Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба - Башкарма комитет);

заказчы;

- экология экспертизасы узарга тиешле планлаштырылган хуҗалык яисә башка эшчәнлек нәтиҗәсендә мәнфәгатьләре турыдан-туры йә читләтеп кузгатылырга мөмкин булган юридик затлар һәм (яисә) индивидуаль эшкуарлар;

- 18 яшькә җиткән һәм Ютазы районы территориясендә яшәгән кимендә 10 кешедән торган гражданнарның инициатив төркеме;

- эшчәнлекләренең территориаль өлкәсе Ютазы районы территориясендә булган иҗтимагый оешмалар һәм берләшмәләр.

1.9. Әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләү нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора:

- билгеләнгән эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохиткә йогынтысы характеры һәм масштаблары, аны гамәлгә ашыруның альтернативалары, әлеге йогынтының экологик һәм аларга бәйле башка нәтиҗәләрен һәм аларның әһәмиятен бәяләү, йогынтыларны минимальләштерү мөмкинлеге турында мәгълүмат;

- заказчы тарафыннан билгеләнгән эшчәнлеккә кагылышлы карарлар кабул иткәндә җәмәгатьчелекнең нәрсәне өстен күрүен ачыклау һәм исәпкә алу;

- ниятләнгән эшчәнлекне гамәлгә ашыруның альтернатив вариантларын билгеләү (шул исәптән объектны урнаштыру урыны турында, технологияләрне сайлау турында һәм башкаларны) яисә, әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны үткәрелгән бәяләү нәтиҗәләрен исәпкә алып, аннан баш тарту турында заказчы карары.

Әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләү нәтиҗәләре экологик экспертизага тапшырыла торган, шулай ук әлеге эшчәнлеккә карый торган башка идарә карарларын кабул итү процессында файдаланыла торган әлеге эшчәнлекнең бер өлеше булган йогынтыны бәяләү материалларында документлаштырыла.

## 2. Иҗтимагый фикер алышуларны оештыру һәм уздыру тәртибе

2.1. Әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләү түбәндәге этаплар белән уздырыла: әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләүне уздыруга техник

биремне алдан бәяләү һәм төзү.

2.2. Беренче этап барышында заказчы:

- билгеләнгән эшчәнлекнең гомуми тасвирламасын үз эченә алган нигезләүче документацияне; аны гамәлгә ашыру максатларын; мөмкин булган альтернативаларны; аны гамәлгә ашыру шартларын тасвирлауны; гамәлдәге норматив документларда каралган башка мәгълүматны әзерли һәм хакимият органнарына тапшыра;

- әлеге Нигезләмәнең 2.3., 2.4 пунктлары нигезендә җәмәгатьчелеккә хәбәр итә;

- 3.2.2 пунктының төп нигезләмәләре буенча алдан бәя бирә һәм аның нәтиҗәләрен документлаштыра;

- әйләнә-тирә мохиткә, шул исәптән кызыксынучы җәмәгатьчелеккә дә йогынты ясауны бәяләү процессында катнашучыларны билгеләү максатыннан, беренчел консультацияләр үткәрә.

Әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны алдан бәяләү барышында заказчы мәгълүматны җыя һәм документлаштыра:

- планлаштырылган хуҗалык һәм башка эшчәнлек турында, аны гамәлгә ашыруның максатын да кертеп, урнаштыру мөмкин булган альтернативалар, сроклары һәм күздә тотыла торган урыны, административ территорияләргә кагыла торган трансчик йогынтысы мөмкинлеге, территориаль һәм тармак планнарына һәм программаларына туры килү;

- йогынтыга дучар ителергә мөмкин әйләнә-тирә мохитнең торышы һәм аның аеруча йомшак компонентлары турында;

- әйләнә-тирә мохиткә мөмкин булган әһәмиятле йогынтылар турында (җир ресурсларына, калдыкларга, транспорт һәм башка инфраструктураларга йөкләнеш, чыгарып ташлаулар һәм ташлаулар чыганаклары (источники выбросов и сбросов)) һәм әлеге йогынтыны киметү яисә булдырмау чаралары.

Йогынты алдан бәяләү нәтиҗәләре нигезендә заказчы әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләүне үткәрүгә техник бирем (алга таба - ТЗ) төзи, аңа түбәндәгеләр керә:

- заказчының (башкаручының) исеме һәм адресы;

- әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләүне уздыру сроклары;

- әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләүне үткәрүнең төп ысуллары, шул исәптән җәмәгатьчелек белән консультацияләр уздыру планы;

- әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләүне уздырганда төп бурычлар;

- әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләү буенча материалларның фаразлана торган составы һәм эчтәлеге.

Техник бирем төзегәндә заказчы әйләнә-тирә мохитне саклау буенча махсус вәкаләтле органнарның таләпләрен, шулай ук әйләнә-тирә мохиткә йогынты ясауны бәяләү процессының башка катнашучыларының фикерен исәпкә ала. Техник бирем әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләү процессында катнашучыларга аларның таләпләре буенча җибәрелә һәм әйләнә-тирә мохиткә йогынты ясауны бәяләүне уздыру вакыты дәвамында җәмәгатьчелек өчен һәркем файдалана ала.

Әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләүне уздыруга техник бирем, әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләү буенча материалларның бер өлеше булып тора.

2.2.1. Ниятләнгән хуҗалык һәм башка төр эшчәнлекнең әйләнә - тирә мохиткә йогынтысын бәяләү буенча тикшеренүләр түбәндәгеләрне үз эченә ала:

- хуҗалык һәм башка эшчәнлек характеристикаларын һәм мөмкин булган альтернативаларны (шул исәптән эшчәнлектән баш тартуны) билгеләүне;

- ниятләнгән хуҗалык һәм башка эшчәнлек (табигый мохит торышы, антропоген йөкләнешнең булуы һәм характеры һ. б.) йогынты ясарга мөмкин булган территориянең торышын анализлау;

- альтернативаларны исәпкә алып, хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохиткә мөмкин булган йогынтысын ачыклау;

- ниятләнгән хуҗалык һәм башка эшчәнлеккә йогынтыларны бәяләү (риск, дәрәҗә, характер, масштаб, таралу зонасы барлыкка килү ихтималы, шулай ук экологик һәм алар белән бәйле социаль һәм икътисадый нәтиҗәләрне фаразлау);

- тискәре йогынтыларны киметүче, йомшарткыч яисә кисәтүче чараларны билгеләү, аларның нәтиҗәлелеген һәм гамәлгә ашыру мөмкинлеген бәяләү;

- әйләнә-тирә мохиткә кала торган йогынтыларның әһәмиятен һәм аларның нәтиҗәләрен бәяләү;

- карала торган альтернативларның, шул исәптән эшчәнлектән баш тарту вариантының күтелгән экологик һәм алар белән бәйле социаль-икътисадый нәтиҗәләре буенча чагыштыру һәм гамәлгә ашыру өчен тәкъдим ителә торган вариантны нигезләү;

- хуҗалык һәм башка эшчәнлекне гамәлгә ашыруның барлык этапларында экологик мониторинг һәм контроль программасы буенча тәкъдимнәр эшләү;

- ниятләнә торган хуҗалык һәм башка эшчәнлекне гамәлгә ашыруга проекттан соң анализ ясау буенча тәкъдимнәр эшләү;

- билгеләп үтелә торган хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохиткә йогынтысын бәяләү буенча материалларның алдан вариантын әзерләү (белгеч булмаганнар өчен кыскача бәян итүне дә кертеп).

2.3. Иҗтимагый фикер алышуларны оештыручы - Башкарма комитет.

Җәмәгатьчелеккә мәгълүмат бирү һәм катнашу әлеге Нигезләмә нормалары һәм башка норматив хокукый документлар нигезендә әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләүнең барлык этапларында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Җәмәгатьчелекнең әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләү материалларын әзерләүдә һәм тикшерүдә катнашуы заказчы тарафыннан әйләнә-тирә мохиткә йогынты ясауны бәяләүне уздыру процессының аерылгысыз өлеше буларак тәэмин ителә, заказчы ярдәмендә һәм Россия законнары нигезендә, җирле үзидарә органнары яисә дәүләт хакимиятенең

тиешле органнары тарафыннан оештырыла.

Әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләүдә җәмәгатьчелеккә һәм башка катнашучыларга хәбәр итү, әйләнә-тирә мохиткә йогынты ясауны бәяләүгә башлангыч бәяләү һәм техник бирем төзү этабында мәгълүмат җиткерү заказчы тарафыннан гамәлгә ашырыла. Мәгълүмат кыска рәвештә җирле үзидарә органнарының рәсми басмаларында басылып чыга, алар территориясендә дәүләт экология экспертизасы объектын гамәлгә ашыру ниятләнә, шулай ук үз территорияләрендә хуҗалык һәм башка эшчәнлек йогынты ясарга мөмкин. Басмада түбәндәгеләр турында белешмәләр бирелә:

- күрсәтелгән эшчәнлекнең исемнәре, максатлары һәм урнашу урыны;
- заказчының яисә аның вәкиленең исеме һәм адресы;
- әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләүне үткәрүнең якынча сроклары;
- иҗтимагый фикер алышуны оештыру өчен җаваплы орган;
- җәмәгатьчелек фикер алышуның фаразланган рәвеше (сораштыру, тыңлау, референдум һ.б.), шулай ук искәрмәләр һәм тәкъдимнәр тапшыру формасы;
- әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләү буенча техник биремне алу сроклары һәм урыны;
- башка мәгълүмат.

2.4. Әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләү процессында катнашучыларга 2.2 пунктта күрсәтелгән өстәмә мәгълүмат белән таныштыру федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында һәм Ютазы районы Уставында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгару (халыкка җиткерү) юлы белән гамәлгә ашырыла.

2.5. Инициатор иҗтимагый фикер алышулар үткәрү буенча эшче төркемгә (алга таба - эшче төркем) кертү өчен гариза, шулай ук инициатордан вәкилләр исемлеген тапшыра.

2.6. Инциатор булып заказчы торган очракта, гаризага әлеге Нигезләмәнең 1.4 пунктында бәян ителгән документлар теркәлә.

2.7. Башкарма комитет инициатор булган очракта, гариза бирү таләп ителми.

2.8. Оештыручы:

- гаризаны карый һәм заказчы тарафыннан тапшырылган документлар составының Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килүен, документны Башкарма комитетта теркәгәннән соң 5 эш көне эчендә тикшерә;
- иҗтимагый фикер алышулар оештырылган очракта, инициатор белән берлектә үткәрү датасын һәм вакытын билгели; бина бирүне оештыра һәм җәмәгать фикер алышулары барышында аудио - һәм материалларны яздыру һәм яңадан торгызу өчен видеоаппаратура куллану, заказчы биргән кирәкле мәгълүмат материалларын күрсәтү мөмкинлеген тәэмин итә;
- әлеге Нигезләмәнең 2.7 пункты нигезендә Башкарма комитетның карары проектын әзерли;
- фикер алышу өчен чыгарыла торган мәсьәләләр буенча махсус белемнәргә ия затларның (алга таба - экспертлар) исемлеген билгели; иҗтимагый фикер алышулар уздырганчы аларга рекомендацияләр һәм

тәкъдимнәр бирү үтенече белән чакыру һәм мөрәҗәгать җибәрә;

- җәмәгатьчелек вәкилләренең документларга керү мөмкинлеген тәэмин итә;

- хәбәрнамә басылып чыккан вакыттан алып 30 календарь көн эчендә җәмәгатьчелек вәкилләреннән килгән искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне кабул итүне һәм документлаштыруны, заказчыга искәрмәләр һәм тәкъдимнәр кертүне тәэмин итә;

- әлеге Нигезләмәнең 2.10 п. нигезендә иҗтимагый фикер алышулар уздыруны оештыра.

2.9. Әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләү буенча материалларның алдан вариантыннан файдалану сроклары һәм урыны, җәмәгать тыңлаулары уздыру датасы һәм урыны турында, 2.2 пунктта күрсәтелгән иҗтимагый катнашуның башка рәвешләре турында мәгълүмат федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында һәм Ютазы районы Уставында билгеләнгән тәртиптә җәмәгать фикер алышулары (җәмәгать тыңлаулары уздыру) тәмамланырга 30 көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарыла (халыкка җиткерелә).

Басып чыгарганда (халыкка җиткергәндә) түбәндәгеләр турында белешмәләр тапшырыла:

- күрсәтелгән эшчәнлек төре, максатлары һәм урнашу урыны;

- заказчының исеме, адресы, телефоны яисә аның вәкиле;

- ОВОС үткәрүнең якынча сроклары;

- заказчының исеме, адресы, телефоны;

- иҗтимагый фикер алышу рәвеше, шулай ук искәрмәләр һәм тәкъдимнәр бирү рәвеше;

- әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләү буенча документлардан файдалану сроклары һәм урыны;

- башка мәгълүмат;

2.10. Басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) материалларның башлангыч вариантлары күчермәләрен оештыручыга җибәрә.

2.11. Эшче төркем эшендә катнашуны тәэмин итә.

2.12. Иҗтимагый фикер алышулар үткәрү турында карар Башкарма комитет карары рәвешендә кабул ителә, анда түбәндәгеләр билгеләнә:

- иҗтимагый фикер алышуларны оештыру өчен нигез;

- эшче төркем составы (эшче төркем рәисе, секретаре һәм эшче төркем әгъзалары. Гомуми сан кимендә 7 кеше;

- әлеге Нигезләмәнең 1.5 пункты нигезендә иҗтимагый фикер алышулар рәвеше;

- иҗтимагый фикер алышулар үткәрелгән очракта - уздыру датасы, вакыты, урыны, тәртибе;

- тәкъдимнәр, рекомендацияләр һәм кисәтүләр ясау вакыты һәм урыны.

Башкарма комитет карары федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында һәм Ютазы районы Уставында аңа кул куйган көннән алып 10 календарь көн эчендә бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

2.13. Эшче төркеме комиссия рәисеннән, секретареннан, инициатордан, оештыручыдан, экспертлардан һәм башка комиссия әгъзаларыннан тора.

2.14. Эшче төркем:

- иҗтимагый фикер алышуларның көн тәртибен әзерли;
- иҗтимагый фикер алышуларның нәтиҗәләрен ачыклый.

2.15. Җәмәгать тикшерүләрен уздыру тәртибе:

2.15.1. Алып баручы (яки эшче төркеме рәисе):

- иҗтимагый фикер алышуларны ача;
- эшче төркем әгъзаларын игълан итә;
- Җәмәгать тикшерүләрен уздыру тәртибен һәм фикер алышуда катнашучыларның чыгыш ясау вакытын игълан итә.

2.15.2. Заказ бирүче яки аның вәкиле дәүләт экология экспертизасы объекты турында кыскача хәбәр итә.

2.15.3. Оештыручы кызыксынучы җәмәгатьчелек вәкилләреннән килгән кисәтүләрне һәм тәкъдимнәрне укый.

2.15.4. Экспертлар, катнашучылар тема буенча кисәтүләр, тәкъдимнәр белән чыгыш ясыйлар, сораулар бирәләр, заказчыдан кергән сорауларга җаваплар алалар.

Чыгыш алдыннан иҗтимагый фикер алышуда катнашучы үзенең фамилиясен, исемен, атасының исемен (Ф.И.А.и.) хәбәр итәргә тиеш, әгәр чыгыш ясаучы нинди дә булса оешманың вәкиле булса, вазыйфасын.

2.15.5. Алып баручы (яки эш төркеме рәисе) иҗтимагый фикер алышуларның төп нәтиҗәләрен китерә, иҗтимагый фикер алышулар беркетмәсен әзерләү, аңа имза салу, искәрмәләр бирү тәртибен аңлата.

2.15.6. Иҗтимагый фикер алышулар беркетмәсе эш төркеме секретаре тарафыннан алып барыла һәм фикер алышуда катнашучыларның чыгышларын (Ф.И.А.и. күрсәтеп), аларның сорауларын һәм җавапларын, тәкъдимнәрен һәм кисәтүләрен бәян итүне үз эченә ала, тавыш бирүдә кабул ителгән карарларга заказчы, эшче төркем рәисе һәм секретарь тарафыннан мәҗбүри тәртиптә имза салына. Беркетмә иҗтимагый фикер алышулар үткәрелгән көннән алып 5 эш көне эчендә төзелә һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайты Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм Порталы составында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырыла.

2.15.7. Шәхси хуҗалык һәм башка эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында карар кабул ителгәнчегә кадәр гражданнардан һәм иҗтимагый оешмалардан язма искәрмәләр һәм тәкъдимнәр кабул итү, әлеге тәкъдимнәрне ОВОС материаллары кушымталарында документлаштыру җәмәгать фикер алышуы тәмамланганнан соң 30 календарь көн эчендә заказчы тарафыннан тәэмин ителә.

## 3. Әйләнә-тирә мохиткә йогынты ясауны бәяләү материалларына таләпләр

3.1. Әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләү материаллары ниятләнә торган хуҗалык һәм башка эшчәнлек дәүләт экология экспертизасы органнары тарафыннан кабул ителә торган әлеге эшчәнлекне гамәлгә ашыру мөмкинлеге турында карарлар кабул итүнең барлык стадияләрендә бирелә.

3.2. Әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләү материаллары техник булмаган характердагы мөһим нәтиҗәләрне һәм әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләү нәтиҗәләрен үз эченә алган резюмны кертергә тиеш.

3.3. Әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләү буенча материалларның составы әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләүне уздыру тәртибе белән билгеләнә, хуҗалык һәм башка эшчәнлек төренә, әлеге эшчәнлекне нигезләүче экологик экспертиза объекты булган документларга таләпләргә бәйле.

3.4. Әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләүне уздыруның тулылыгы дәрәҗәсе(детальность) хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең билгеләнгән масштабына һәм төренә һәм аны гамәлгә ашыруның күздә тотыла торган төбәгенең үзенчәлекләренә бәйле.

3.5. Әйләнә-тирә мохиткә планлаштырылган хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең инвестиция проектлауда йогынтысын бәяләү буенча материалларның типлаштырылган эчтәлеге район Башкарма комитетының норматив хокукый акты белән раслана.

3.6. Ниятләнгән хуҗалык һәм башка эшчәнлек документлары файдалану мөмкинлеге чикләнгән мәгълүматка кертелергә мөмкин булган очракта, заказчы әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны мәгълүмати ачыклык принцибы нигезендә бәяләү материаллары әзерли.